**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
от 02.11.2020 года

**РЕШЕНИЕ**
№02-08

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертүне раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 20, 21 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектына үзгәрешләр кертү хакындагы 2020 елның 03 августындагы 10-53/9670 номерлы бәяләмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1.Актаныш муниципаль районы Советының 2013 елның 28 мартындагы 27-07 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына муниципаль районның электр белән тәэмин итү картасын территориаль планлаштыру схемасын әзерләү һәм тулыландыру өлешендә үзгәрешләр кертүне расларга.

2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм расланган документны Россия Федерациясе территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Совет Рәисе Э.Н.Фаттахов